РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

**ЧИСТАЙ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

---

***Решение*** ***Карар***

**2019 елның 23 нче октябре** **Чистай шәһәре** **№40/2**

Чистай шәһәр Советының
2016 елның 10 ноябрендәге
9/1 нче номерлы “Җир салымын түләү
ставкасын, тәртибен һәм срокларын
билгеләүне гамәлгә кертү турында”гы
Карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексына кертелгән үзгәрешләр нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Советы

**Карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының 2016 елның 10 ноябрендәге “Җир салымын түләү ставкасын, тәртибен һәм срокларын билгеләүне гамәлгә кертү турында”гы 9/1нче карарына (Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының 07.08.2017 елгы 16/3нче, 27.06.2018 елгы 26/3нче, 23.11.2018 елгы 29/2нче, 07.10.2019 елгы 39/3 нче карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктның 1.1 пунктчасындагы 3 абзацында “(физик, юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә)” сүзләрен “(эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш)” сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны “Чистопольские известия”(“Чистай хәбәрләре”) газетасында бастырырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый-мәгълүматлар порталында (pravo.tatarstan.ru), шулай ук Чистай муниципаль районының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендәге рәсми сайтында (www.chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарныңүтәлүенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә О.В. Добронравовага йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәре башлыгы Д.А.Иванов